<table><tr><td>МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН</td><td></td><td>ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ</td></tr></table>

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

30.12.2021 Казан ш. № 4176-р

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын урнаштыру турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп һәм «Энергоцентр «Майский» АҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Фонд пространственных данных Республики Татарстан» дәүләт бюджет учреждениесе хатын истә тотып (16.11.2021 № 1485/05), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан газ бүлү челтәре объектының («Энергоцентр Майский» АҖ газ исәбе узелы» корылмасының саклык зонасы») саклык зонасын, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, газ бүлү челтәренең характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, гомуми мәйданы 719 +/- 9 кв.м.лы территория рәвешендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Н.В.Захаровка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**